# Муллахметов Хузиахмат-участник первой мировой войны

Муллахмәтов Хуҗиәхмәт 1892 елда Алабуга өязе Салагыш волостендагы Бәзәкә авылында Муллахмәт Габделгафаров (1866 елгы) һәм Шәмседоха Шакирова (1867 елгы) гаиләсендә дөньяга килә. 1897 елда перепись вакытында гаиләләрендә әбисе Сәрбиҗамал Рафыйкова (1822 елгы), абыйсы Миннегәрәй (1890 елгы), сеңлесе Миннеҗиһан (1894 елгы) була. Бәлки алга таба аларның гаиләсендә тагын балалар тугандыр, ләкин бу турыда архивта документлар таба алмадык (А.Х.Мәхмүтова. “Колыбель моя, Бизяки”, стр.436, п.28). Хуҗиәхмәт абзый авылдашларыбыз Галиәхмәт Муллахметов, Әнвәр Хуҗиәхметов һәм Тәскирә Шәрәфиеваларның (Хуҗиәхмәтова) әтисе була.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 27 | Мух-шакир Г-насыров | 41 | башк | мус | | |
| | Шамсидуха Мух-янова | 36 | | | | |
| | Миниахмат | 11 | | | | |
| | Кадыча | 7 | | | | |
| | Латифа | 3 | | | | |
| 28 | Муллаахмет Г-гафаров | 31 | башк | мус | | |
| | Сарбизамал Рафикова – м | 75 | | | | |
| | Шамсудуха Шакирова – ж | 30 | | | | |
| | Минигарай | 7 | | | | |
| | Хузаахмет | 5 | | | | |
| | Минизиган | 3 | | | | |
| 29 | Ахтамьян Г-гафаров | 43 | башк | турки | У муллы | |
| | Шамсидуха Г-каримова-ж | 35 | | | У муллы | |
| | Нигаматьян | 8 | | | У муллы | |
| | Ахметхан | 5 | | | | |
| | Нурмухамет | 2 | | | | |
| 30 | Мух-вали Шамсутдинов | 88 | башк | мус | | |
| | Минизиган Зайнибаш. – ж | 60 | | | | |
| | Габдурахман – с | 22 | | | | |
| | Миниахмет – с | 18 | | | | |
| | Банят – дочь Габд. | 5 | | | | |
| | Гульзиган – д. М-в | 19 | | | | |
| 31 | Хазиахмет Мухаметьянов | 31 | башк | мус | У муллы | |
| | Гульзиган Гимазетдинова | 29 | | | У муллы | |
| | Загира Бикмух-ва – мать | 62 | | | У муллы | |
| | Сахибулахмет | 6 | | | | |
| | Минихадия | 2 | | | | |
| 32 | Шигабутдин Тойгунов | 58 | башк | Тур (за-черкн) | Все учились у муллы | |
| | Минивафа Габдуллина | 55 | | | | |
| | Муфтахутдин | 22 | | мус | | ополч. 2-разр. |

436

Хуҗиәхмәт абзый, яшенә караганда, солдат хезмәтенә беренче бөтендөнья сугышы башланганчы ук алынган булырга тиеш. Ул 73 –нче Крым пехота полкында хезмәт итә һәм полклары белән 1914 елда сугышка кереп китә. 1916 елның 6 июнендә Хуҗиәхмәт абзый Көнбатыш Украинаның бүгенге Львов өлкәсендәге Городок районына кергән Тучаны авылы янындагы сугышларда яраланып (“сквозное пулевое ранение правой стопы”) башта Псков шәһәренең Александров общинасының күчмә лазаретына (бу Псков шәһәрендә оештырылып фронтка җибәрелгән лазарет) урнаштырыла. Аннан 1916 елның 20 июнендә Хуҗиәхмәт абзый Одесса шәһәр больницасы каршындагы лазаретка җибәрелә.

Архивларда Хуҗиәхмәт абзыйның сугышчан биографиясенә кагылышлы башка документлар табып булмады. Сугыш беткәч ул Бәзәкәгә кайта, тормыш корып җибәрә.

Түбәндә Хуҗиәхмәт абзыйның кызы Тәскирә апа Шәрәфиеваның истәлекләрен китерәбез:

**Әтәй һәм әнәй турында язма**

Минем бабай Муллахмәт, әби Шәмседоха Бәзәкә авылында туып, шунда гомер кичергәннәр. Аларның ике уллары һәм ике кызлары булган, шушы ике кызы авырып үлгәннәр, ә минем әтәй Хуҗәхмәт һәм аның энесе Гәрәй исән-сау калганнар.

Әтәй Хуҗәхмәт 1892 елда туган, 1963 елның 10 маенда үлде. Әнәй Газиз кызы Хәдичә 1898 елда туган, 1968 елны 12 декабрендә үлде.

Әтәйне 1914 елны Беренче бөтендөнья сугышына алган булганнар, ул аннан яраланып кайткан.

Әтәйнең абыйсы Гәрәй 1890 елгы Магнитогорск шәһәрендә яшәп үлде-аларны анда авылдан кулак дип җибәргәннәр, юкса бер сыеры, бер аты булган. Өйләре хәзерге мәчет урынында була, иске өйләре хәзер зиратта тора, бабайлар мәет өзатканда шунда кереп торалар. Гәрәй абыйның 5 баласы булган.

Әтәйнең беренче хатыны Нәгыймә апа-ул авырып үлгән һәм әтәй Хәдичә әнәйгә өйләнгән. Әтәйнең Нәгыймә ападан кызы Нәсимә туып-өч яшьтән ятим калган, аны инде әнәй үстергән. Нәсимә апа безнең Бәзәкә авылында эшләп яшәде, аның Марсель, Мансур, Мехаматнур исемле малайлары булды.

Әтәй белән әнәй көндез колхозда эшләделәр, ә төнлә әтәй колхоз конторысында каравылчы булып эшләде. Безнең өй ике катлы булды, шуның асты кибет, ә өйнең икенче ягы пекарня иде. Әнәй шунда төнлә каравылда торды. Әтәй белән әнәйне авылда бик хөрмәт иттеләр.

Әтәй белән әнәйнең балалары-Нуриәхмәт, Накыя, Хаҗи, Галиәхмәт, Әнвәр һәм мин, Тәскирә, туганбыз.

Нуриәхмәт абый 1923 елгы, Бөек Ватан сугышыннан кайтмады, 1942 елның 14 августында елда һәлак булган, Смоленск өлкәсе, Гагарин районы Сапешно авылында җирләнгән дип әйттеләр. Накыя апа-1926 елгы, башта колхозда урман кисүләрдә йөргән, ә мин белгәндә пекарныйда озак еллар эшләде, аннан почтада почтальон булып эшләп лаеклы ялга китте. Накыя апаның бер малае Ильдар булды.

Хаҗи абый-1932 елгы, армияга киткәнче колхозда эшләде, кайткач "ЕУРБ"да нефтяникларда эшләп, шуннан лаеклы ялга чыкты. Хаҗи абыйның өч малае-Рәис, Ринат, Хаҗинур бар.

Галиәхмәт абый 1936 елгы, башта колхозда эшләде, аннан грузчик булып сельпода эшләде, нефтяниклардан эшләп лаеклы ялга чыкты. Аның биш баласы-Зөфәр, Рамиль, Ильдар, Ләйсән, Рашат булды.

Әнвәр абый 1940 елгы, биш ел колхозда электрик булып эшләде. Аннан Чаллы шәһәрендә ГЭСта электрик булып эшкә керде, шуннан лаеклы ялга чыкты. Абыйның ике малае-Айрат белән Альберт бар.

Үзем Тәскирә-1944 елгы, 11 класс бетереп бер ел мәктәптә эшләдем, аннан Бәзәкә ашханәсендә эшләдем һәм калган эш урыным-НГДУда лаборант, оператор ТХУ булып эшләп лаеклы ялга чыктым. Минем ике балам бар-Люзия белән Ильшат.

Бугенге көндә әтәй белән әнәйнең җиде баласы арасыннан мин генә исән, аллага шөкер. Апалар, абыйлар инде вафат, алар барсыда алтын куллы иделәр, урыннары җәннәттә булсын!

Шарафеева Тәскирә Хуҗәхмәт кызы. 12.02.2024 ел.

## **Муллахметов Хазиахмет** *(Хузиахмет)*

Ранен/контужен. Именные списки потерь

Должность/Звание: рядовой

Воинская часть: 73-й пехотный Крымский полк

Место рождения: Вятская губ., Елабужский уезд, Салаушская вол.

Причина выбытия: ранен/контужен

Дата события: 06.06.1916

Место события: д. Тучаны (Западная Украина, Львовская область, Городокский район, село Тучаны)

Тип документа: Именные списки потерь

Архив: Российский Государственный Военно-исторический архив

Фонд: №16196, Особое делопроизводство по сбору и регистрации сведений о выбывших за смертью или за ранами, а также пропавших без вести воинских чинах, действующих против неприятельских армий (1914 - 1918)

Опись: №1, Именные списки потерь солдат и офицеров 1 мировой войны 1914-1918 гг. (по полкам и бригадам)

Дело: №183, Списки потерь солдат 73 пехотного Крымского полка

Документ: №166320, Именной список потерь нижних чинов 73 пехотного Крымского полка за июнь 1916 года, Автор: 73-й пехотный Крымский полк, 1916-09-22

Список проверен 5/IV-21 год
О. Аватурова

398

~~288~~/278

Начальнику Штаба 19 пѣхотной дивизии.


ОСОБОЕ ОТДѢЛЕНІЕ
22 СЕН. 1916 -166320
ГЛАВНАГО ШТАБА

№ 2

Именной списокъ

потерь нижнихъ чиновъ 73 пѣхотнаго Крымскаго полка.

За Іюнь 1916 года



# Мулахметов Хазю Ахмет *(Муллахметов Хузиахмет)*

Ранен/контужен. Картотека потерь

Должность/Звание: рядовой

Воинская часть: 73-й пехотный Крымский полк

Место рождения: Вятская губ., Елабужский уезд, Салаушская вол., д. Безяки

Причина выбытия: ранен/контужен

Дата выбытия: 06.06.1916

Дата события: 11.06.1916

Тип документа: Карточка на прибывших (нижние чины)

Архив: Российский Государственный Военно-исторический архив

Фонд: Картотека бюро учета потерь в Первой мировой войне (офицеров и солдат)

Шкаф: без номера

Ящик: 2260-М

1032

(Синія для нижн. чиновъ).

**На прибывшихъ.**

Фамилія Мулахметовъ

Имя Хазю Ахметъ

Отчество

Воинское званіе и часть Рядов. 73-го Крымскаго полка

Губернія Вятская

Уѣздъ Елабужская

Волость Салаушская

Селеніе (деревня, станица) дер. Бязаки

Боленъ

Раненъ скв. пул. ран. прав. стопы

Время и мѣсто сраженія 6 Іюня 916 г.

Названіе и подробный адресъ лазарета, сообщающаго свѣдѣнія (штемпель)

ПОДВИЖН. ЛАЗАРЕТЪ

Псковск. Алексѣев. Общины сест. милосер. Красн. Креста.

Когда поступилъ въ лазаретъ 11 Іюня 916 г.

ПСКОВСК. АЛЕКСѢЕВ. ОБЩ.

www.gwar.mil.ru

**Мухахметов Хазиахмет** *(Муллахметов Хузиахмат)*

Ранен/контужен. Картотека потерь

Должность/Звание: рядовой

Воинская часть: 73-й пехотный Крымский полк

Место рождения: Вятская губ., Елабужский уезд, Салаушская вол.

Причина выбытия: ранен/контужен

Дата выбытия: 06.06.1916

Дата события: 20.06.1916

Место события: Австрийский фронт


Тип документа: Карточка на прибывших (нижние чины)

Архив: Российский Государственный Военно-исторический архив

Фонд: Картотека бюро учета потерь в Первой мировой войне (офицеров и солдат)

Шкаф: без номера

Ящик: 2276-М


948. 520

(Синія для нижн. чиновъ). На прибывшихъ.

Фамилія Мухамедовъ

Имя Хазіахметъ

Отчество

Воинское званіе и часть Ряд 73 Крымск. полк

Губернія Вятск

Уѣздъ Елабужск

Волость

Селеніе (деревня, станица)

Боленъ

Раненъ

Время и мѣсто сраженія

Названіе и подробный адресъ лазарета, сообщающаго свѣдѣнія (штемпель)

Одесской отряд

Когда поступилъ въ лазаретъ 20/XI

1016

Түбәндә Хуҗиәхмәт абзый хезмәт иткән полкның кыска тарихы белән таныштырабыз:

# Крымский 73-й пехотный полк

**73-й пехотный Крымский Его Императорского Высочества Великого Князя Александра Михайловича полк** — пехотная воинская часть Русской императорской армии. Входил в состав 19-й пехотной дивизии.

## Формирование и кампании полка

Сформирован на Кавказе 17 апреля 1856 г., в составе 5 батальонов, из 1, 2, 3, 4 и 5-го Черноморских линейных батальонов, под названием *Крымский пехотный полк*. 5-й Черноморский линейный батальон, сформированный в 1842 г. из Нашебургского пехотного полка, передал в Крымский полк следующие знаки отличия: Георгиевское знамя с надписью: «За оборону крепости Баязет 20 и 21 июня 1829 г.» и серебряные трубы с надписью: «Нашебургского полка 1814 г. августа 30 в воздаяние отличных подвигов против французских войск».

С первых дней своего существования Крымский полк принял деятельное участие в тяжёлой борьбе с горцами на Черноморской береговой линии. 23 апреля 1857 г. 3 батальона перешли Кубань и в течение трёх лет работали на постройке Адагумской укреплённой линии. Последующие 4 года прошли для полка в многочисленных экспедициях и стычках с горцами, закончившихся полным покорением Западного Кавказа. Боевая служба Крымцев на Кавказе была отличена пожалованием всему полку знаков на шапки с надписью: «За отличие при покорении Западного Кавказа в 1864 г.»

25 марта 1864 г. к названию полка был присоединён № 73 и полк приведён в следующем году в 4-батальонный состав. 1 апреля 1866 г. сын Главнокомандующего Кавказской армией, великий князь Александр Михайлович, был назначен шефом, и полку присвоено название 73-го пехотного Крымского Его Императорского Высочества Великого Князя Александра Михайловича полка.

1 августа 1874 г. от Крымского полка был отделён один батальон, пошедший на формирование 162-го пехотного Ахалцыхского полка.

Перед началом русско-турецкой войны 1877—1878 гг. полк был мобилизован и назначен в состав Эриванского отряда. Простояв в Эривани до начала военных действий, крымцы 18 апреля перешли границу и заняли Баязет. Оставив 2 роты в Баязете, полк двинулся в Армению и доблестно участвовал 4 и 9 июня в боях при Драм-Даге и с. Даяр. Отступив затем на выручку осажденного Баязета, Крымцы совершили тяжёлый поход и после упорного сражения 28 июня с 13-тысячным корпусом освободили гарнизон. Охраняя затем границу Эриванской губернии от вторжения турок, крымцы участвовали 23 и 28 октября во взятии укреплённой позиции у Деве-Бойну и в неудачном штурме Эрзерума. За мужество и храбрость, оказанные в турецкую войну, полку был пожалован 13 октября 1878 г. «поход за военное отличие»[1] и добавлена надпись на Георгиевское знамя: «За дела 4 и 9 июня и освобождение Баязета 28 июня 1877 г.». 7 и 8-я роты, входившия в состав Баязетского гарнизона и геройски выдержавшие 23-дневную осаду, были награждены 13 октября 1878 г. Георгиевскими рожками с надписью: «За геройскую защиту Баязета с 6—28 июня 1877 г.».

В 1880—1881 г. 9 и 10-я роты приняли участие в Ахал-Текинской экспедиции генерала Скобелева и за штурм Геок-Тепе были награждены 9 июня 1882 г. знаками на шапки с надписью: «За взятие штурмом крепости Геок-Тепе 12 января 1881 г.».

Полковой праздник — 30 августа.

Дислокация: Винница, Кавказский военный округ

1917 елгы переписьта Хуҗиәхмәт абзый үзе күрсәтелми, ә әтисенең гаиләсе генә язылa (алар әле бер хуҗалык булып торганнардыр): Гафаров Муллахмәт һәм хатыны белән 2 улы, 2 килене һәм 2 оныгы тора (А.Х.Мәхмүтова. “Колыбель моя, Бизяки”,стр.482, п.68). Шулай ук Муллахмәт абзыйның Бондюг заводында подрядта эшләгәне күрсәтелгән.

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 67 | Гафаров Метемьян<br>ж.60, 3с. 27,23,11, вн. 1, сн. 24,22, д. 9 | 64 | 5 | 2,1 | 1, 16 | 4 | 25 | 25 | 4 | | |
| 68 | Гафаров Муллахмет-подрядч. Б.з.<br>ж.55, 2с. 28,27,2вн. 1,2,2сн. 28,25, в.2 | 55<br>ар. | 4<br>4н. | 2 | 4 | 10 | 32,5 | 35 | 2 | 2 | |
| 69 | МухамедьяновХазей<br>ж. 46,2с. 23,19,<br>4д. 22,14,12,10, сн. 21 | 54 | 5 | 2 | 2,1 | 12,8 | 25<br>1,5л | 6,5 | 6<br>о, 5к | 6 | 1,5гр |
| 70 | Валеев Габдрахман<br>ж. 40,2с. 23,15,<br>5д. 16,10,8,6,3 | 53 | 4 | 2 | 2,2 | 8 | 20 | 12 | 1,5 | 8 | 2 яч. |
| 71 | Шигабетдинов Алялетдин<br>ж.30, д. 1,5 | 33 | 1,5 | 1 | 1,16 | 2 | 8 | 9 | | | |
| 72 | Шигабетдинов Фардетдин<br>ж.25, 2с.5и1, д. 3 | 30 | 1,5 | 1 | 1,1 | 3,3 | 7,5 | 10 | | | |
| 73 | Шигабетдинов Мифтахетдин<br>ж.33, 4с. 20,13,5,3, д. 8 | 45 | 3,5 | 1 | | 4 | 18 | 8 | 8 | | |
| 74 | Тазетдинов Фатахетдин<br>ж.47, с. 15, 2д. 14 и 9 ар. 3н. | 48 | 2 | 1 | 1 | 5 | 25 | 25 | 3 | | 2 яч. |
| 75 | Сиразетдинов Ахмадетдин<br>ж. 55,7с. 32,25,20,13,10,8,6, сн., 3д. 17, | 66<br>14 | 4<br>11 | 2<br>вн. 1 | 2,2 | 2,4 | 20 | 20 | 5 | | 0,5<br>лен |
| 76 | Гилязетдинов Гильман – отсутств.<br>Землю сдал в аренду № 74 | 19 | 3 | | | | | | | | |
| 77 | Сиразетдинов Гильфанетдин<br>ж.35, с. 10, 3д. 15,13,2 | 45 | 3 | 1 | 2,1 | 3,2 | 15 | 19,5 | | | |
| 78 | Давлетшин Гарей<br>ж.35, 3с. 10,7,6, 2д. 5и3 | 35 | 1 | 2 | 1 | 3 | 5 | 6,5 | | | |
| 79 | Мухаметдинов Гильфанетдин<br>ж.32, с. 10, 2д. 3и1 | 32 | 1 | | | | 5 | 6,5 | | | |
| 80 | Мухаметдинов Виста<br>с.18, д. 19 | 40 | 2 | 1 | 1,1 | | 10 | 6,5 | 6 | | |
| 81 | Динмухаметов Сахабутдин<br>ж.60, 2с.21и8, 2д. 16и10 | 60 | 3 | 2 | 2,1 | 6,2 | 15 | 8 | | 5 | |
| 82 | Динмухаметов Фазлиахмет<br>ж.60, 4с. 32,29,28,20, д. 18 | 60 | 5 | 2,1 | 1,1 | 5 | 25 | 25 | 5 | | |
| 83 | Динмухаметов Миниахмат<br>ж.50, 2с.18и3, 3д. 19,10,5 | 49 | 3 | 2 | 2 | 5,1 | 15 | 12 | 2 | 2 | 4 яч. |
| 84 | Тазетдинов Хисаметдин<br>ж.40, с. 16, 2д. 17,13, м.66 | 50 | 4 | 4 | 2,1 | 3 | 20 | 18 | 4 | 4 | |



1925 елгы переписьта Хуҗиәхмәт абзыйны әтисе фамилиясе белән Гафаров Хуҗиәхмәт дип язганнар. Аның гаиләсендә 6 кеше була: болар әти-

әнисе, хатыны белән үзе һәм 2 баласыдыр инде (А.Х.Мәхмүтова. “Колыбель моя, Бизяки”,стр.504, п.78).

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 75 | Шиябутдинов Авзалетдин | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 76 | Закиров Фатах | 5 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 77 | Шакиров Миниахмат | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 78 | Гафаров Хузахмат | 6 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 79 | Гафаров Гарай | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 80 | Шабаев Муфтах | 8 | 1,52 | 1,6 | 3,12 |
| 81 | Давляшин Гарай | 9 | 1,52 | 1,6 | 3,12 |
| 82 | Серазетдинов Гильфан | 6 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 83 | Ахмадянов Назиб | 9 | 1,71 | 1,8 | 3,51 |
| 84 | Шибаев Фарди | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 85 | Шибаев Аглей | 7 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 86 | Тазетдинов Фатах | 5 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 87 | Хадеев Минахмат | 7 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 88 | Ахмадянов Исхак | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 89 | Мухамедянов Хисами | 8 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 90 | Шайгалямов Фатах | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 91 | Хисматуллин Давлей | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 92 | Гайнутдинов Багаутдин | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 93 | Гайнутдинов Зайнутдин | 7 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 94 | Сахабутдинов Возит | 3 | -76 | -80 | 1,56 |
| 95 | Хисамутдинов Насиб | 7 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 96 | Гимазетдинов Авзалетдин | 6 | -95 | 1 | 1,95 |
| 97 | Мухамадянов Галиахмат | 7 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 98 | Альмухаматов Миниахмат | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 99 | Фазлеев Хузя | 4 | -57 | -60 | 1,17 |
| 100 | Хафизов Закир | 7 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 101 | Закиров Ахун | 2 | -19 | -20 | -39 |
| 102 | Хубихузин Фардей | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 103 | Якопов Минихан | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 104 | Сагабутдинов Харамай | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 105 | Мухамедянов Хузя | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 106 | Альмачева Фазиля | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 107 | Насыров Хуснутдин | 10 | 1,9 | 2 | 3,9 |
| 108 | Шакиров Фархи | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 109 | Газизов Сахаб | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 110 | Гимазетдинов Гильфан | 7 | 1,52 | 1,6 | 3,12 |
| 111 | Шарафеев Галимян | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 112 | Хазеев Сахибулахмат | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 113 | Якопов Фатхий | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 114 | Денеев Галиахмат | 2 | -38 | -40 | -78 |
| 115 | Денеев Миниахмат | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 116 | Набиуллин Галимулла | 6 | -95 | 1 | 1,95 |
| 117 | Гилфанутдинов Гимазетдин | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 118 | Шарипов Галли | 4 | -57 | -60 | 1,17 |
| 119 | Бикмухаметов Галиахмат | 8 | 1,52 | 1,6 | 3,12 |
| 120 | Набиуллин Гатаулла | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 121 | Муфтиев Миниахмат | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 122 | Гимазтинов Гауни | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 123 | Мусинов Закир | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 124 | Гайнутдинов Мухамат | 3 | -76 | -80 | 1,56 |
| 125 | Арсланов Багаутдин | 4 | -95 | 1 | 1,95 |
| 126 | Арсланов Даулат | 2 | -57 | -57 | 1,17 |

504

20-нче гасырның 30-нчы елларында Хуҗиәхмәт абзый колхозга кергән беренче бәзәкәлеләр арасында була (А.Х.Мәхмүтова. “Колыбель моя, Бизяки”, стр.513, п.32).

## № 12. 1931 елда колхозга кергән бәзәкәлеләр исемлеге

| №№ | Фамилия, имя, год рождения | №№ | Фамилия, имя, год рождения |
|---|---|---|---|
| 1 | Шәяхмәтев Ясәви 1886 | 24 | Мәхмүтов Хаҗиәхмәт 1900 |
| 2 | Зәйнеттинев Фәттахи 1898 | 25 | Гыйззәтуллин Нәбиулла 1888 |
| 3 | Гайнетдинов Баһау 1879 | 26 | Гомәров Хәмәт 1916 |
| 4 | Шәйдуллин Хаҗи 1913 | 27 | Хөрмәтуллин Сибәгат 1914 |
| 5 | Ситдыйкова Гайшә 1878 | 28 | Гыйлфанов Гаптелхак 1914 |
| 6 | Исмәгыйлев Шәйми 1901 | 29 | Шибаев Әһли 1876 |
| 7 | Хәсәнов Зәйнетдин 1880 | 30 | Бикмөхәмәтев Тимерша 1916 |
| 8 | Зиннуров Мулланур 1913 | 31 | Шибаев Фәрди 1881 |
| 9 | Мәүләвиева Минниса 1883 | 32 | Муллахмәтов Хуҗахмәт 1888 |
| 10 | Шәйдулатов Мөхәмәтша 1914 | 33 | Зиннатуллина Латифа 1863 |
| 11 | Нәбиуллин Ясәви 1902 | 34 | Фазуллин Шәех 1904 |
| 12 | Сабитов Шәхми 1898 | 35 | Газизов Сәхип 1899 |
| 13 | Низаметдинов Кәшфи 1886 | 36 | Нәбиуллин Хәким 1909 |
| 14 | Шәрипов Минтәчтин 1905 | 37 | Исламова Фәхернур 1873 |
| 15 | Гыймадиев Хәмәт 1907 | 38 | Кәримов Хаҗи 1914 |
| 16 | Газизов Гәрәй 1921 | 39 | Әхмәтҗанов Нури 1870 |
| 17 | Ибәтуллин Садыйк 1893 | 40 | Башаров Госман 1889 |
| 18 | Шакиров Мөхәмәтҗан 1875 | 41 | Төхфәтуллин Гәрәй 1893 |
| 19 | Көләчев Габдулла 1883 | 42 | Төхфәтуллина Минебәдәр 1917 |
| 20 | Фәтхуллин Муллахмәт 1886 | 43 | Бикмөхәмәтев Фәтхи 1904 |
| 21 | Исхаков Гыйлаҗ 1863 | 44 | Баһаветдинов Касыйм 1903 |
| 22 | Гимашев Нәҗметдин 1875 | 45 | Габидуллин Габдулла 1905 |
| 23 | Баһаветдинова Фәтхия 1900 | 46 | Гафаров Зариф 1874 |

*Исемлек Бәзәкә авыл советы архивында саклanучы 1937–1939 елларның хуҗалык кенәгәләреннән алынды.*

## № 13. Акт ревизии работы Бизякинского сельсовета за 1933 год

*Күчермә*

**Акт**

1934 ел 29 гыйнвар Татарстан җөмһүрияте Алабуга районы Бәзәкә авыл советы тикшерү комиссиясе әгъзалары Шакиров Ф., Ахмитҗанов Х., Садыков Гата, авыл советы рәисе ярдәмчесе Гиздәтуллин Н, язучы Мәхмутов Х.-ларның катнашы белән Садыков рәислеге астында Бәзәкә авыл советының 1933 елның 1 гыйнварыннан алып 1934 елның 1 гыйнварына кадәр эшләп килгән эшләре буенча тикшерү алып уза.

*(1–2 бүлекләр – авыл советы составы хакында – А.М.)*

Ш. Авыл советының хуҗалык яклары.

Барлыгы 515 хуҗалык, шулардан колхозниклар 202 ялгыз хуҗалыклар 313 хуҗалык, шулар эчендә аерымнарда җирле хуҗалыклар 226, җирсез хуҗалыклар 87. Җан хисабы 2342; колхозчылар – 842 җан, аерымнар – 1500. 1933 елда 87 җан туган, 94 үлгән.



***Муллахметов Хужҗиәхмәт***





*Муллахметов Хуҗиәхмәт улы Нуриәхмәт белән ( Нуриәхмәт Бөек Ватан сугышында 1942 елда Смоленск өлкәсендә һәлак була)*



*Хуҗиәхмәт абзый балалары белән*



Нәби абый һәм Гайшә апа, Мансур җизнәй 1әм Накия апа, Хаҗи абый һәм Фәйрүзә җингәй, Рәис һәм мин (Тәскирә)



*Гәрәй (Минегәрәй) Муллахметов Чиләбедән Бәзәкәгә кунакка кайткач энесе Хуҗиәхмәт белән*



*Тәскирә Шарафиева (Хуҗиәхмәтова) әнисе Шәмседоха белән*



*Муллахметов Галиәхмәт Хуҗиәхмәт улы*



*Муллахметов Хажи Хужиәхмәт улы*



*Тәскирә һәм Әнвәр Хуҗиәхмәтовлар*




*Тәскирә Шәрәфиева кызы Люзия, киявe Фәрхәд Шаяхметовлар гаиләсе белән*